**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань / Казан ш. **БОЕРЫК**

703-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча Комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 05.07.2022 № 577-п, 10.04.2023 № 428-п, 06.06.2023 № 695-п 06.05.2025 № 462-п, 20.10.2025 № 1250-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 07.04.2022 № 258 - п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү Комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан И.И. Садриевны чыгарырга.;

Комиссия составына кертергә:

Кузнецов Максим Дмитриевичны - Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгече - Комиссиянең җаваплы сәркатибе.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Радиоактив калдыкларны, I-V класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималы саклагычларыннан, тау чыганакларын, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата башка корылмаларны ликвидацияләүнең һәм консервацияләүнең техник проектларыннан тыш, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы тарафыннан карауны һәм килештерүне оештыру турында» (06.05.2025 № 463 - п, 20.10.2025 № 1250-п

боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 05.09.2023 № 1031-п боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән боерык белән расланган, Радиоактив калдыкларны, I-V класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималы саклагычларыннан, тау чыганакларын, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата башка корылмаларны ликвидацияләүнең һәм консервацияләүнең техник проектларыннан тыш, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын килештерү буенча Комиссиясе турындагы Нигезләмәдә:

3.1 пунктта «13» саннарын «11» саннарына алмаштырырга;

Күрсәтелгән боерык белән расланган, Радиоактив калдыкларны, I-V класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималы саклагычларыннан, тау чыганакларын, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата башка корылмаларны ликвидацияләүнең һәм консервацияләүнең техник проектларыннан тыш, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын килештерү буенча Комиссия составында:

Комиссия составыннан И.И. Садриевны, Р.А. Федорованы чыгарырга.;

Кузнецов Максим Дмитриевичның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгече - Комиссиянең җаваплы сәркатибе.».

3. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенә әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары А.А. Тугушевка йөкләргә.

Министр  А.И. Җиһаншин